КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 3 июнь г.Казань № 771

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карары белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 14 гыйнвар, 11 нче карары белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта «48 пунктында» сүзләрен «49 пунктының бишенче һәм алтынчы абзацларында» сүзләренә алмаштырырга;

49 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Агымдагы финанс елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр субсидия алучы Министрлыкка агымдагы финанс елының декабре өчен түбәндәге хисапларны тапшыра:

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырудан башкарылган чыгымнар һәм алынган керемнәр турында һәм дәүләт тарафыннан тарифлар җайга салынуга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәр күләмнәре (субсидия алучы эшенең техник-икътисадый күрсәткечләре) турында;

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән гражданнарның кайбер категорияләренә юл йөрүгә түләү өчен ташламалар бирү турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән гражданнарның кайбер категорияләрен йөртүдән алынып бетмәгән керемнәре турында хисап.»;

53 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

58 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

59 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин